РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Исполнительный комитет**
**Осинниковского сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
***Осинниковское авыл жирлеге***
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Молодежная , 9А, пос.Осинники, 422824
тел. (8843)77 3-39-29 факс: (8843)77 3-39-29
e-mail:adm@kama-tamagy.gov.tatarstan.ru
ИНН/КПП 1622004651/162201001

Молодежная урамы, 9А, п.Осинники, 422824,
тел. (8843)77 3-39-29 факс: (8843)77 3-39-29
e-mail:adm@kama-tamagy.gov.tatarstan.ru
ИНН/КПП 1622004651/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2021 елның 29 гыйнварыннан** **№1**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлегендә 2021 елга җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәт күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләргә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә 6424 сум 98 тиен күләмендә бәя куярга һәм 2021 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2020 елның 30 гыйнварындагы 2 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль

районының Осинники авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Осинники п., Яшьләр ур., 9А йорт (административ бина);
- Осинники п., Лесная ур., 2 йорт (Осинники мәдәният йорты);

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга .

4. Әлеге карар 2021 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Х.Сәгъдиев

Кама Тамагы муниципаль районы
Осинники авыл җирлеге башкарма
комитетының 2021 елның 29
гыйнварындагы 1 номерлы карарына
1 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлегендә җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3850,02 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (мәетне ) зиратка илтү | 547,86 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2027,10 |
| Барлыгы | 6424,98 |

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль Осинники авыл җирлеге
башкарма комитетының 2021 елның 29
гыйнварындагы 1 номерлы карарына
2 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлегендә җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 197,58 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3652,44 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (мәетне) зиратка илтү | 547,86 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2027,10 |
| Барлыгы | 6424,98 |